| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.03.2026 Буа шәһәре №45-п

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен төзү һәм аларны әзерлек хәләндә тоту турында» 2017 елның 23 октябрендәге 111/п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы һәм «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен төзү һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 июлендәге 496 номерлы карарын үтәү йөзеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын билгеләнеше буенча куллануга даими әзерлектә тоту, хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халыкны хәвеф-хәтәрләрдән яклауны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен төзү һәм аларны әзерлек хәләндә тоту турында» 2017 елның 23 октябрендәге 111/п номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Абзац 5 пункт 3 :

г) сигезенче абзацта «хәрби конфликтлар яисә шушы конфликтлар килеп чыкканда, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «куркынычлар килеп чыгу нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга.;

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарылырга тиеш (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа
муниципаль районы башлыгы вазыйфаларын башкаручы
И.Ф.Еремеев